КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
Декабристов ул., 2, г. Казань, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«16» декабря 2016 г. № 45-П

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының, вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2010 елның 30 сентябрендәге Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва иткән гражданнарның керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырулары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырулары турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указын тормышка ашыру максатында боерам:

1. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының, вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларының исемлеген расларга (алга таба – Вазыйфалар исемлеге).

2. Кадрлар бүлеге баш белгече Т.А.Желтухинага:

аларны эштән азат иткәндә Вазифалар исемлегенә кертелгән вазифаларны биләгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләр, бурычлар һәм җаваплылыклар турында аңлатырга;

бу боерыкны Вазифалар исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә;

Вазыйфалар исемлеген, расланган көненнән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт идарәсенә тәкъдим итәргә, алга таба, аңа үзгәрешләр кертелгәндә, үзгәрешләр кертелгән исемлекне үзгәрешләр кертелгән көннән алып бер атна вакыт эчендә тәкъдим итәргә.

3. Юридик бүлекчә мөдире Н.Е.Романовага әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Коррупцион һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат А.А.Сметанинага «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы сайтына, «Коррупциягә каршы тору» бүлегенә урнаштырырга.

5. «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2013 елның 15 августында «Дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» № 13-п/1 боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Бу Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкченең урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы, җитәкченең беренче урынбасары — Э.Ф.Әхмәтова

«Татмедиа» Республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгының
16.12.2016 № 45-п боерыгы
белән расланган

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының, вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын үтәгәндә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалар исемлеге

Баш төркем вазыйфаларының «җитәкче» категориясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

җитәкченең беренче урынбасары;

җитәкченең урынбасары.